ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ютазинская, д.14А,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ютазы урамы, 14А йорт,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 6-23-33, факс:6-25-28, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 14**

**КАРАР**
**29 октябрь 2024 ел**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкә авыл җирлегенең Бәйрәкә торак пунктында
гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Уставының 23 маддәсенә ярашлы, КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 11 ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм Абдуллин, Авангард, Вахитов, Кооперация, Минһаҗев урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2024 елның 12 ноябрендә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм Октябрь, Пушкин, Сельхозтехника, Татарстан урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. 2024 елның 12 ноябрендә 14.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә торак пунктында Бәйрәкә авылында теркәлгән һәм Тукай, Ютазы, 1 Май, 8 Март урамнары буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2025 елда Бәйрәкә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм ветераннардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында

хезмәт итүчеләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы; әлеге түләүне бер тапкырга киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчы белән техниканы арендалау, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү));

- Бәйрәкә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Абдуллин урамындагы юл-урам челтәрен (чокырларны ремонтлау) норматив хәлгә китерү);

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, электр тарату пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (лампалар, энергияне сак тота торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (проект-смета документлары, материал сатып алу, урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- халыкның күпләп ял итә торган урыннарын (паркларны, скверларны, яр буйларын, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзекләндерү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (материаллар, җайланмалар сатып алу, су агып яту урыннарын бетерү, торбаларны алыштыру, эш өчен килешү буенча түләү).

- Бәйрәкә торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар тоту, (зират территориясендә карт агачларны кисү, агачларны химик эшкәртү (химик препарат сатып алу), эш өчен килешү буенча түләү));

5. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 26 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Бәйрәкә авылы, Ютазы ур., 14А йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә;

- Бәйрәкә торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Бәйрәкә торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетына Бәйрәкә торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), http://pravo.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга. 5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы: А.О.Әхмәтшина